## МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕНДА КАРАЛГАН КАЙБЕР ПРОЕКТЛАР (Янә бер проект)[1]

Собрание даирәсенә [тирәсенә] дахил [катнашучы, керүче] мөселманнарның хаҗәтләрен бәян кылып, министрлар шурасының назарына тәкъдим кылынмыш проектның нөсхәсе корылтай мәҗлесләрендә укылып, маддәләренең әксәре [күбесе] кабул кылынып, дүрт маддә гыйлавә [өстәмә] кылынмыштыр. 12 хәзрәт каләме илә имза кылынмыш нөсхәдән алып, ул проектны да бу раддә яздым. Шул: «1903 сәнәдә игълан кылынмыш фәрман шаһанәдә, 1904 сәнә декабрь 12 һәм 1905 сәнә февраль 18 фәрман шаһанәләрендә император хәзрәтләре бөтен милләтләргә хөррияте диния ихсан [ярдәм, булышлык] итте. Россия мөселманнары да император хәзрәтләренең бу бөек ихсаннарына наил улды. Дин тотмакта хөрриятемез там [тулы, бөтен] исә дә, дини эшләремезне матлуб [тиешле, кирәк] рәвештә идарә итмәк өчен, безем янә шул хаҗәтләремез дә канун куәте илә безгә вирелсә иде:

1. Россиядә бөтен вилаятьләрдә, областьларда мөнтәшир [җәелгән] улып, әксәренең фәкыйрьлеге өчен бөтен мөселманнарны бер мәркәздә генә тупламак авырлыгына күрә, тиеш җирләрдә хаҗәт кадәре шөгъбәләр тәэсис кылынса иде.

2. Собрание, бөек бер мәхкәмәи исламия улмак сыйфаты илә, ялгыз дахилия назаратына [эчке эшләр министрлыгына] табигъ кылынып [буйсынып], вилаят правлениеләренә табигъ улмактан югары чыгарылса иде.

3. Мөфти милләт ихтыяры илә гомерлек сайланып, император хәзрәтләре тарафыннан, казыйлар халык ихтыяры илә алты сәнәлек сайланып, дахилия назары тарафыннан тәсдыйк кылыныр.

4. Даирәсенә дахил руханилар тиешле мәсьәләләрдә мөшавәрә өчен собрание дәгъвәт итә [чакыра] булыр.

5. Хөкүмәт, начальство яхуд бөек мәхкәмәләрнең бере тарафыннан берәр мөһим мәсьәлә хакында фәтва я рәи [караш, фикер] соралса, собрание ялгыз үзе генә җавап вирмәеп, моктәдир руханиларның, могтәбәр зыялыларның мөшавәрәләренә мөрәҗәгать итәр.

6. Коръәни Кәримнең, дини китапларның табигына [бастыруына] назарат [күзәтү, контроль] собрание ихтыярына хәсыр кылыныр [билгеләнер].

7. Низам каршында тәгаен кылынмыш яшьләренә ирешмәгән кыз-егет үз ризалыгы илә никахны ихтыяр итсәләр, вөҗүдләренең тәхмиленә бакып [гәүдәләренең чыдавына карап], зарурәт [үтә кирәклек] сәгатьләрен игътибарга алып, собрание рөхсәт вирә булыр.

[1] Җарулла Муса. Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. Б. 91–105. Дәвамы. Проектларның бер өлеше «Фәнни Татарстан» журналының 2 нче санында дөнья күрде. Б. 75–85.

8. Мәҗүсиләрдән [потка табынучылардан, язычниклардан] бере исламият кабул итеп, мөселманнардан беренең никахына рәгъбәт [омтылыш] итәр исә, собрание рөхсәт вирә булыр.

9. Яһүдиләрдән [еврейлардан], православие мәзһәбенә, башка нәсраниятьтән [христианлыктан] бере мөселманнардан беренең никахына рәгъбәт итәр исә, собрание рөхсәт вирә булыр.

10. Мөселманнарның нәсранияләрдән, яһүдиләрдән туган балалары ислам дәфтәренә кайд кылынып [теркәлеп], мөселман игътибар кылыныр.

11. Ата-бабалары ислам рәсемендә [гадәтендә] гомер итмеш керәшен нам мөселманнарны собрание ислам дәфтәренә, ислам мәхәлләләренә кайд итә булыр.

12. Христиан руханиларына канун тарафыннан вирелмеш хокукларның һәммәсе ислам руханиларына да вирелер.

13. Имин алыначак урыннарның һәрберендә, мөселманнарның имине үз лисаннарында, ислам руханилары хозурында улыр.

14. Ислам хаҗиләренең паспортлары рус паломникларының паспортлары бәһасендә улыр.

15. Мәктәп-мәдрәсәләргә, мәсҗедләргә, тәрбия йортларына, шифаханәләргә, гомумият илә хәер максатларының һәрберенә һәр җирдән иганә тупламак ихтыяры мөселманнарга да вирелер.

16. Русларның ибтидаи, урта дәрәҗә мәктәпләренең һәрберендә ислам балаларына дин, лисан, язу дәресләре укытмак өчен собрание ислам мөгаллимнәре тәгаен итәр.

17. Гаскәри хезмәтендәге мөселманнар мәгаш [хезмәт хакы] һәм рәтбә [дәрәҗә, звание] хосусларында руслар илә бер хокукта улыр.

18. Ислам гаскәри өчен тиешле микъдарда [чамада] имамнар нәсыб кылыныр [хезмәткә билгеләнер].

19. Штаб имамнары христианнарның штаб руханилары илә бер хокукта улыр.

20. Руханилар, собрание әгъзалары русча ценздан азат кылыныр.

21. Руханилар хезмәт гаскәриядән азат кылыныр.

22. Руханилар хәбестән [кулга алудан, аресттан] азат улыр.

23. Шәхсыятьләрен [үз файдаларын кайгыртуларын] тәгъриф [белдерү, аңлату] юлында фотограф чыгартмак зәхмәте илә руханилар тәклиф [боеру, көчләп кушу] кылынмас.

24. Руханиларга хәзинә мөһере вирелеп, мәхкәмәләргә күндереләчәк рапортлары, гаризалары мөһерләнмеш исә, почтада мәҗанән [түләүсез, бушка] кабул кылыныр.

25. Чит мәмләкәтләрдә тәхсил итмеш рус тәбгасы мөселманнарга мөгаллим, мөдәррис я рухани булынмак хакы вирелер.

26. Мәсҗед бинасына мөсагадә хосусларында христиан руханиларының берәр сурәт илә мөдахәләләре [катышу, кушылулары] катгыян мәнгы [тыю] кылыныр.

27. Дини китаплар, чит мәмләкәт табигы улса да, дәстхат [кулъязма] улса да, мәктәп-мәдрәсәләрдә, мәсҗедләрдә мәмнугъ [тыелган] улыр.

28. Христиан кәлисәләренең [чиркәүләренең] биналарына, тәгъмирләренә [төзекләндерүгә, ремонтка] хәзинә урманнарыннан, земство сәрмаяларыннан носыл иганә кылыныр исә, ислам мәсҗедләренең биналарына да, тәгъмирләренә дә ул илә иганә кылыныр.

29. Мәсҗед бинасының рәсмият җәһәте собрание мөсагадәсе [булышуы, ярдәме] илә тәмам улыр.

30. Мөселман гаскәренә намаз, руза кеби үзләренең фараз гыйбадәтләрен, мөгаен вакытларында әда итмәк [үтәү], һәм дә җомга көннәрендә, бәйрәм көннәрендә штаб имамнары хозурында җомга, гает намазларын укымак мөсагадә кылыныр.

31. Мөселман гаскәренә хинзир [дуңгыз], хәмер кеби хәрам тәгам [ризык], хәрам шәраб вирмәк катгый мәнгы кылыныр [тыелыр].

32. Ислам, Коръәни Кәрим, шаригъ хәким [шәригать законнарын төзүче] хәзрәтләренә тагын [сүгү, хурлау], тәшнигъ [гаепләү, хурлау] юлында нәшер кылынмыш рисаләләргә, мәкаләләргә мокабәлә итмәк [каршы тору] ихтыяры, һәр мәсъүлиятьтән [җаваплылыктан] азат улмак тәэмине илә, мөселманнарның һәрберенә мөсагадә кылыныр.

33. Россия дәүләтендә, биля истисна [чыгармасыз] һәр җирдә, җир-йорт имляк [милекләр] сахибы улып җирләшә белмәк хакы Россия мөселманнарына руслар кеби биля шарт [шартсыз] вирелер.

34. Дәүләтнең ибтидаи [башлангыч], урта, бөек мәктәпләренең һәрбере ислам балаларына һәрвакыт ачык улыр.

35. Башкорт, кыргыз балалары ислам мәктәпләренә, мәдрәсәләренә һәрвакыт кабул кылыныр. Татар, башкорт шәкертләренә кыргыз арасында мөгаллим, мөдәррис, имам улмак хакы вирелер.

36. Тәгълим йортларына кабул кылыначак ислам балаларыннан үзләренең дин, лисан, язуларын белүләре хакында ибтидаи мәктәп шәһадәтнамәсе [таныкламасы] таләп кылыныр.

37. Рус мәктәпләрендә укучы ислам балаларының ислам дәресләренә инабәтле [ышанычлы] мөгаллимнәр васитасы илә [ярдәме белән] собрание һәрвакыт назарат итәр [күзәтер].

38. Иртидад итәчәк [диннән чыгачак] адәм балигъ түгел [несовершеннолетний] исә, гаризасы кабул кылынмас. Балигъ исә, собрание хозурында бер ай мөддәт [ара, вакыт] вәгазь-нәсыйхәт кылынмак гариза мәкъбүлияте [кабул ителү] өчен шарт улыр. Бунын хилафына [кире, каршы] хәрәкәт итәчәк адәмнәр, инсанның диненә тәгадди [гаделсезлек] итмеш улмак гөнаһы илә, низам каршында мәсъүл [җаваплы] улыр.

39. Мөселманнарның әхлакларын төзәтмәк, адабе динияләрен тәгълим итмәк, дөнья хәлләреннән хәбәрдар итмәк өчен үзләренең лисаннарында җәридә [газета], мәҗәллә [журнал], рисаләләр [брошюралар] нәшеренә мөсагадә вирелер.

40. Никах, нәсәб [нәсел-ыру, чыгыш], мирас, ризаг [сөт имү], хазана [өлеш, пай], талак, гадәт

кеби гаилә мәсьәләләре һәм дә буңа мөтәрәттиб [тәртипләнгән] мөһер нәфәка ижра кеби хокукы малияләр һәммәсе ислам руханиларының мәгърифәтләренә, ихтыярларына тәслим кылыныр [бирелер].

41. Һибә [бүләк, буш бирү], васыять, вакыф кылынмыш милекләргә шәригатьнең хөкемнәрен иҗра кылып, тиешле кәгазьләрен тәсдыйк итмәк кодрәте собраниегә вирелер.

42. Вәрәсәдән [варислардан] бәгъзеләре сабый яки гаиб [югалган] улыр исә, собрание васый [опекун] нәсыб итәр [билгеләр].

43. Хассалары [өлешләре] шәригатькә муафыйк тәгаен кылындыктан соң, хасса кәгазьләрен мәхәллә руханилары тәсдыйк итә булыр.

44. Бөтен варисларның гадәден [санын] бәян итеп, тәкъсим [бүлү] хосусында гариза вирүчеләргә собрание үзе хассаларын тәгаен һәм тәсдыйк итәр.

45. Имамнар мөселманнарның дин башлары улмакларына күрә, голүме диниядә ысулдан, фөругтан [кисәк, бүлемнәрдән] камил дикъкать һәм игътинаэ итеп [әһәмият биреп], хатиплык, мөдәррислек имтиязларына [рөхсәтләренә] имтихан итмәк собрание икътидарына [көченә] махсус улыр.

46. Эшләренең, карарларының һәммәсеннән собрание һәр өч айда бер дәфга [кат, тапкыр] дахилия назаратына [Эчке эшләр министрлыгына] иҗмал дәфтәре [конспект, кыскача аңлатма] мәэмүрият [вазифа, командировка] гарыз итәр.

47. Вилядәт [туу], вафат, никах, талак хәдисәләрен [вакыйгаларын] кайд итмәк [беркетү] өчен метрика дәфтәрләре табгы иттереп [бастырып], даирәсенә дахил [тирәсенә кергән] мәхәллә имамнарының һәрберенә үзенең шөгъбәләре, ахундлары яхуд волость правлениеләре, шәһәр полицияләре васитасы [арадашлыгы] илә собрание нәшер итәр.

48. Метрикә дәфтәрләре төркичә язылыр.

49. Метрикә дәфтәрләренең дөреслеген тәфтиш [тикшерер] һәм мокабәлә иттерер [чагыштырыр].

50. Берәр сәбәп илә кайд кылынмаеп калмак вилядәт, никах, талак, вафаты метрикә дәфтәренә кайд иттермәк гариза илә соралыр исә, мәкъбүл гозерләрен исбат итеп сәнәләрен дә ачык тәгаен тәкъдирендә, собрание тиешле урыннарына кайд иттерер.

51. Һәм мәхәллә руханиялары, һәм собрание метрикә дәфтәрләреннән сәнәд [документ] кәгазе бирерләр.

52. Имамнар кулында метрикә дәфтәре мәгъзүр [гозерле] бер сәбәп илә тәләф улып [югалып, бозылып] соралыр исә, нөсхәләрен собрание яздырып күндерер.

53. Мөселманнардан алыначак имин сурәтләрен тәрҗемәсе илә бәрабәр табгы иттереп [бастырып], тиешле урыннарына собрание таратыр.

54. Собраниедән күндерелеп мәхәлләгә исаль [тапшыру, китереп бирү] кылыначак кәгазьләрне, дәфтәрләрне полиция тиешле урыннарына исаль итәр.

55. Мөнасиб [яраклы] җирләрдә тәрбия йортлары ачмак, җәмгыяте хәйрияләр тәэсис итмәк [оештыру] хакы да собрание икътидарына вирелер.

56. Җәмәгать тарафыннан сайланмыш адәм имтиханда әһлияте сабит [яраклы] улып, әхлак вә истикамәте [намуслылыгы] тәхкыйк [шиксез] кылындыктан соң, мәхәлли правлениеләрнең мөдахәләсеннән [катышуыннан] башка, ялгыз собрание ихтыяры илә тәсдыйк кылыныр. Указ, русча тәрҗемәсе илә бәрабәр, татарча улыр.

57. Сайланмыш руханиларның нәфәкасы [яшәү өчен кирәк булган азыгы] җәмәгать зиммәсенә [йөкләмәсенә] илзам кылыныр.

58. Руханилардан я шәригать, я низам хилафына берәр эш садыр улыр исә, гөнаһның дәрәҗәсенә күрә, бәгъдел тәфтиш [тикшергәннән соң] я тәнбиһ [кисәтү, искәртү], я гыйтаб [шелтә, орышу] яхуд газел итмәк [хезмәттән чыгару] ялгыз собрание икътидарында улыр.

59. Бөтен вазыйфаларын хак илә ифа итәчәге [үтәве] һәм дә хилаф [каршы] низам, хилаф шәригать һичбер хәрәкәттә булынмаячагына газеми [кискен ният] хосусында руханилардан мәнсабларына тәгаен сәгатьләрендә собрание имин алыр.

60. Шәригать җәһәтеннән назар кылыначак эшләре ислам руханилары васитасы илә собрание тәфтиш иттерер.

61. Мәхәллә җәмәгате илә имам арасында яхуд руханиларның ма бәеннәрендә [ике араларында] низаг [талаш] чыгар исә, собрание фасыл [аерым карар] итәр.

62. Бөек мәхәлләләре я җан, я ханә хисабы илә тәкъсим зарур улыр исә, тәкъсим мөсагадәсе собрание назарына мәхсур [чикләнгән] улыр.

63. Имамәт өчен яшь ля әкалле [ким дигәндә] 22 улып, ахундлык өчен ля әкалле 30 улыр.

64. Руханилар гыйбадәт, дини гамәл, шәргый рөсүм [салым, пошлина] кеби бөтен вазыйфаларын биля косур [кимчелексез], биля тәхәллеф [кичектермичә], иминнәренә муафыйк сурәттә ифа итәрләр.

65. Руханилар мәхәллә җәмәгатьләренә гүзәл әхлак, истикамәтле хәят хосусларында вәгазь-нәсыйхәт итәрләр.

66. Мәхәлләдә бер хатип, бер имам, бер мөәзиннән артык нәсыб кылынмас.

67. Ир җан хисабы 200 дән аз җирләрдә бер имам, бер мөәзин я бер хатип, бер мөәзиннән артык нәсыб кылынмас.

68. Руханиларга бер ай я зиядә мөсамәхә рөхсәте вирмәк собрание назарына махсус улыр.

69. Мәхкәмәләр я низами идарәләр тарафыннан хәвалә [бер эшне икенче берәүгә йөкләү, тапшыру] кылыначак хезмәтләрне башкарып, иҗрәтләрен [үтәүләрен] таләп юлында рапорт илә руханиларның мөраҗәгатьләре соңында тиешле иҗрәтләрен собрание вирер. Бу илә иҗрәтләрне вирә белмәк өчен собрание махсус мая [нигез, капитал] тәшкил итәр.

70. Мәхкәмә тарафыннан руханиларга хәвалә кылынмыш дәгъваларда руханилар ике

тарафның һәрберен мөмкин кадәр солых [килешү, ризалашу] җәһәтләренә дәгъвәт итәр. Солых мөяссәр [җиңел, җайлы] улмас исә, шәригатьнең карарына муафыйк хөкем итеп, мәхкәмәягә рапорт язар.

71. Һиляլнең сөбүтенә [яңа айның шиксез барлыкка килүенә] мөтәвәккыйф [бәйләнгән] гыйбадәтләрдә ахундлардан, руханилардан мәгълүмат тупладыктан соң кабул кылынмыш карарын һәммә руханиларга собрание игълан итәр.

72. Мәсҗеде юк карьяларда мәсҗед бинасына рөхсәт алмак өчен гадәд шарт улмас.

73. Яңа мәсҗед бина итмәк өчен җәмәгатьнең приговоры шарт улып, иске мәсҗедне тәгъмир [төзү, яңарту] рөхсәте өчен имамның рапорты кяфи [җитәрлек] улыр.

74. Зарурәт икътиза [үтә кирәклек] итәр исә, мәсҗеде капамык ялгыз собрание назарына махсус улыр.

75. Мәктәпләр, дини мәдрәсәләр собрание идарәсендә улып, билвасита дахилия назаратына табигъ улыр.

76. Мәктәп-мәдрәсә ачмак хосусында собраниедән рөхсәт алыныр, яхуд б혀налары тәмам улып ачтыктан соң собраниега игълам кылыныр.

77. Мәктәп-мәдрәсәләргә назараты өчен собрание муафыйк имамнарны, мөдәррисләрне тәгаен итәр. Назыйрлар шәкертләрнең әдәби җәһәтләренә, дәресләренә мөгаллим-мөдәррисләрнең тәгълимнәренә дикъкать итәр.

78. Үзенә табигъ мәктәпмәдрәсәләр хакында собрание махсус дәфтәрләр тотар.

79. Шәкертләр, дәресләр, китаплар, мөгаллимнәр, мөдәррисләр хакында тиеш мәгълүматны һәр сәнә җәмгы итәр.

80. Собрание һәр сәнә һәр мәдрәсә шәкертләрен имтихан иттерә белер.

81. Дини китапларны мәдрәсә сәнәләренә, таләбәләрнең әхваленә күрә һәр мөдәррис үзе интихаб итә [сайлый, аралап ала] белер. (Корылтай мәҗлесләрендә шул проект укылып, маддәләренең эксәре мәгъкуль күрелдегеннән соң, янә дүрт маддә зиядә кылынмыш.)

82. Собрание һәр һәфтә [атна] алты көн эш күреп, җомгаларда, ислам бәйрәмнәрендә, падишаһ көннәрендә тәгътыйль итәр [ял итәр, туктап торыр].

83. Һәммә Россия мөселманнары җомга, гаед көннәрендә, Царский көннәрдә тәгътыйль кылып; якшәмбеләрдә, христианнарның дини праздникларында тәгътыйль итмәсләр.

84. Руханилар җомга, бәйрәм көннәрендә һичбер хезмәт өчен һичбер мәхкәмә тарафыннан дәгъвәт кылынмас.

85. Мөбарәк Рамазанда мөселман гаскәри билкөллия [бөтенләй, тулысынча] азат улыр. Һич улмаса, тәгамнәре, чәйләре ифтар, сәхәр сәгатьләренә татбикъ кылыныр.

Корылтай мәҗлесләренә риясәт итмеш дамелла Габдулла хәзрәт Апанай имзасы илә бәрабәр 12 хәзрәт 85 маддәдән гыйбарәт шул ляихәдә имза итмешләр.

Шурага кадәр нәкыль кылынмыш проектларның, ляихәләрнең маддәләре бере дигәренә

тәмам мотабикътыр, яхуд бере дигәренең нөсхәседер. Башкалык аз мөтәхалиф маддәләре дә вар. Интикадимы соңра [тәнкыйтьтән соң] бәлки язармын, хәзер хикәят юлына дәвам итәем.

**Министрлар шурасына виреләчәк петиция ляихәсенә материал улмак үзрә мөхтәрәм Хәсәнгата казый хәзрәтләре тарафыннан хәзерләнмеш маддәләр:**

1. Мөселманнарның гыйбадәтләре, дини эшләре тәмам үз ихтыярларында улып, руханиларын нәсыб итмәк, газел итмәк, мәктәп-мәдрәсәләрне идарә итмәк; судларга, төрмәләргә, гаскәрләргә, рус мәктәпләренә мөгаллимнәр, имамнар тәгаен итмәк кеби эшләр һәм дә никах, талак, мирас, нәфәка кеби гаилә эшләре ялгыз собрание ихтыярына махсус улса иде.

2. Собрание үзенең хәзерге гайре табигый хәленнән, ягъни түбәнлегеннән, ялгыз әмернамәләр илә генә идарә кылынмак интизамсызлыгыннан чыгарылса иде. Бәлки бөек рухани мәхкәмә игътибар кылынып, һәр җәһәте законда ачык тәгаен кылынмыш хосусый маддәләр илә идарә кылынса иде.

3. Буннан соң мөфти иң мөмтаз дин галимнәреннән халык ихтыяры илә сайланса иде. Патриарх кеби бөек руханилардан, вәлиләрдән түбән хисап кылынмаса иде.

4. Собрание әгъзалары да халык тарафыннан сайланып, нәсыб та, газел дә мөфтиләрнең мөдахәләләре булынмаса иде.

5. Әгъзалар низам кашында да казый аталып, мәгашләре ля әкалле 1200 рубля улса иде. Өч сәнә мөддәт илә генә сайланып читтән килүләренә күрә, казыйларга да квартира һәм җиһаз хәзерләнсә иде.

6. Собрание секретаре бөек образование сахибы улмак шарт улып, мәгаше дә ля әкалле 1200 улса иде. Өстәл түрәләренең дә мәгашләре, тәрҗеманнарның мәгашләре зиядә кылынса иде.

7. Собраниенең үзенә махсус типография лязимдер. Метрика дәфтәрләре, мәхәллә руханиларына, мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәренә, назарларына циркулярлар, әмернамәләр, дәстүрләр, китаплар, нәсыйхәтләр халык һәм гаскәргә хаҗәт ула булачак зикерләр, дәгъвалар собрание матбагасында табгы кылыныр.

8. Собрание матбагасында табгы кылыначак шәйләрнең һичбере собрание карары булынмадыкча цензура вирелмәс.

9. Собрание әгъзаларына, чиновникларына хәзинә тарафыннан вирелеп килә торган жалованиеләрен тиешенчә арттыру өчен, собраниенең башка хәраҗатларын [чыгымнарын] да тәэмин итү өчен, һәрбер туган бала башыннан, һәр никахтан, һәр мирастан мөгайян [билгеләнгән] бер микъдар [чама, өлеш] рәсми алыныр.

10. Собрание карарларын, фәрманнарын, мохабәрәләрен [хәбәрләшүләрен], руханиларның интикал [күчү, урын алмаштыру], газел [хезмәттән чыгару, урыннан төшерү], вафатларын, мөселманнарның мирасларын, дини я гыйльми мәкаләләре нәшер итмәк өчен айлык бер мәҗәллә [журнал] нәшер кылынып, халык мөгайян

бәһасе илә иштиракь итеп [уртак булып, катнашып]; руханилар, мөгаллим-мөдәррисләр мөмтаз [югарырак] бәһасе илә, әлбәттә, иштиракь итәр.

11. Мәхәллә руханилары искечә халык ихтыяры илә сайланып, собраниедә имтихан кылынып тәсдыйк кылыныр.

12. Ислам руханилары, мөгаллим-мөдәррисләре собраниедән магадә [башка, бүтән] һичбер җиргә табигъ [буйсынучы] улмас. Анларга юнәләчәк әмер, фәрманнар, сөаль-фәләннәр собрание васитасы [арадашлыгы] илә юнәлер.

13. Ислам руханилары һәр хокукта православие руханилары кеби улыр. Һәм дә ата-баба сословиесеннән хисап кылынмаеп, духовный сословиедән хисап кылыныр. Карья руханилары крестьянский судларга табигъ улмас; гаскәр хезмәтенә алынмас, государственный, земской, мирской налоглар түләмәс. Ләкин җир, тиҗарәт [сәүдә, сату] виргуләрен вирер.

14. Руханиларның гаиләсе дә руханилык хокукы илә файдаланыр.

15. Мәхәллә руханиларының җәмәгать тарафыннан хосуллары [керем, файдалары] һәр сәнә, һәр көн noксанда [кимчелекле, җитешсез]. Руханиларның мәгашләре өчен никах, талак, вилядәт, вафат кеби даими хосул мәнбәгъләрыннан [чыганакларыннан] мөгайян бер микъдар алыныр. Карья җирләрендә һәр басу саен бер микъдар җир һәм печәнлек вирелер. Шәһәр җирләрендә я квартира, я йорт хәзерләнеп вирелер.

16. Руханиларга русчадан ценз ихтыярый улыр.

17. Мәхәллә руханиларына гүзәл әхлак, истикамәт [намуслылык, турылык] шарт кылыныр. Һәр җомгада вәгазь сөйләмәк; тугрылык, пакьлек юлларына күндерү, яхшылык хосусларында рәһбәрлек [җитәкчелек, юлбашчылык] итү руханилар үзәрендә иң бөек вазыйфа улыр.

18. Имтихан өчен собраниедә мәгълүм вакытлар тәгаен кылыныр. Имтихан сәгатьләренә руханилар һәм дә мәхәллә җәмәгатьләре дә дәгъвәт кылыныр. Имтихан кылыначак адәмнәрдән голүме шәргыя һәм дә үзләренә лазем закон маддәләре, өстләренә лазем хезмәт вазыйфалары, мәхәллә җәмәгате илә могамәлә әдәпләре соралыр.

19. Мәктәп-мәдрәсәләр дәресләренең програмнары мәгариф назаратыннан чыгарылып, халык ихтыярына тәслим кылынса иде. Собраниедә әһлияте исбат кылынмыш әфәнделәр арасыннан мөгаллим, мөдәррис сайламак хакы да, идарә җәһәте дә халык ихтыярында улыр.

20. Мәктәп-мәдрәсәләрнең һәммә җәһәтләрен идарә итеп, Уфа собраниесенә һәр сәнә хисап вирелеп тормак өчен, халык үз араларыннан өч-дүрт яхуд дәһа зиядә [тагын да күбрәк] мөтәвәллиләр [мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кешеләр] интихаб итәрләр [сайлап алырлар]. Арадан бере рәис улыр. Мөтәвәллиләрнең исемнәрен, фамилияләрен, сыйфатларын собрание махсус дәфтәрләрдә забыт итәр [язып куяр].

21. Дини мәдрәсәләрдә һәммә голүме диния, һәмдә тиешенчә

мәгариф гомумия тәхсил кылыныр. Дини мәдрәсәләр өчен дәрес китаплары интихаб итеп тәгаен итмәк бер һәйәте гыйльмия мәгърифәтенә тәслим кылыныр.

22. Дини мәдрәсә дәресләрен тәмам итеп руханилык хезмәтләренә хәзерләнмеш шәкертләр, әлләрендә [кулларында] собрание шәһадәтнамәсе булыныр исә, хезмәт гаскәриядән азат улыр. Һич улмаса студентлар кеби бер сәнә хезмәт илә иктифа [канәгатьләнү] кылыныр.

23. Мәхәллә мәктәп-мәдрәсәләренә дә мәхәллә руханилары мөгаллим, мөдәррис, мөтәвәлли ула булыр.

24. Мәктәп-мәдрәсә нәфәкасы [яшәү өчен кирәк булган малы (азыгы)]: 1) земстволардан алыныр, христиан мәктәпләренә земство никадәр вирер исә, ислам мәктәп-мәдрәсәләренә дә улкадәр вирер; 2) әһле хәйратның [садака бирүченең] хосусый иганәләреннән, ихсаннарыннан [ярдәм, булышлыкларыннан]; 3) вар исә, вәкыфлардан; 4) мәктәп-мәдрәсәләрдә укучы шәкерт башыннан.

25. Һәр мәктәп, һәр мәдрәсә үзенең шәкертләренә шәһадәтнамә вирер.

26. Әгәр дә халыкның бәхетенә каршы Россиядә гомуми тәгълим мәҗбүри улыр исә, мәктәп-мәдрәсә шәһадәтнамәсе кяфи [җитәрлек] хисап кылыныр.

27. Мөселманнар өчен махсус учительский школаларда инспекторлар, мөгаллимнәр мөселманнан улмак шарт улыр.

28. Учительский школа сыйныфларына кабул кылынмак өчен яшь шарт улмас, бәлки рәгъбәте [теләге, омтылышы] вар һәм адәм, нәкадәр яшь исә дә, кабул кылыныр.

29. Учительский школаларда голүме диния учительский семинарияләрдә «Закон Божий» кадәр укылыр. Дин мөгаллимнәре собрание тарафыннан тәгаен кылыныр.

30. Учительский школаларда таләбәләрнең тәрбиясе, хәяте һәр җәһәт илә исламның милли-дини әдәпләренә муафыйк улыр.

31. Учительский школалардан чыгачак мөгаллимнәр ибтидаи мәктәпләрдә ислам балаларын тәгълим, тәрбия итәчәкләренә күрә, учительский школа дәресләре мөселманнарның ихтыяҗларына, заруратларына, файдаларына мөнасиб сурәттә тәртип кылынса иде. Рус тарихы илә бәрабәр төрек тарихы да, ислам тарихы да; рус грамматикасы илә бәрабәр төрек нәхүы [синтаксисы] да, сарыфы [морфологиясе] да укылса иде.

32. Рус мәктәпләрендә ислам балалары өчен дин мөгаллиме куелып, рус балаларының дин дәресләренә никадәр сәгать тәкъдир кылынса, ислам балаларының дин дәресләренә дә улкадәр тәгаен кылыныр.

33. Тиҗарәт [сәүдә], санаигъ кеби хосусый мәктәпләрне мөселманнар тәэсис итә белсә иде, ул мәктәпләрне хокук җәһәте илә хөкүмәт мәктәпләре кеби улса иде.

34. Мәктәпләрнең береннән шәһадәтнамәсе вар мөселман һәр җәһәт илә: хокук җәһәте илә дә, урын хезмәт алмак җәһәте илә дә руслар илә бер дәрәҗәдә хисап кылынса иде.

35. Мөселман гаскәри мөмкин кадәр бер җирдә тупланып, имам тәгаен кылыныр. Русларның военный попларына хәзинәдән никадәр вирелер исә, гаскәр имамнарына да улкадәр вирелер. Мөхарәбә [сугыш] заманнарында имамнар арттырылыр.

36. Мөселман гаскәриләренә, рус мәктәпләрендә укучы ислам балаларына русларның гыйбадәтләре сәгатендә һәм дә диннәрен тәгълим сәгатьләрендә хазир улмак [шунда булу, катнашу] мәҗбүри улмаса иде.

37. Цензура алга кылынсын. Һич булмаса ислам китаплары да гомуми цензура уставларына табигъ улып [буйсынып], хосусый цензура бетсен. Цензура статьялары гаять ачык төзелеп, ислам китаплары өстендә цензорларга шалить итәрлек урын калмасын.

38. Әдәби, фәнни, дини, сәяси рисаләләр, җәридәләр, мәҗәлләләр нәшер итмәк хосусларында һичбер сурәт илә тарлык кылынмасын, әүвәлдәге кеби миссионерлык кылучылардан рәи [караш, фикер, уй] соралмасын.

39. Земстволарда, шәһәр думаларында дин һәм җенсиять башкалыгы игътибар кылынмасын, мөселманнар һәр хосуста русларга бер дәрәҗәдә игътибар кылынсын, мөселманнарны мәхрүм итә беләчәк высокий цензлар бетсен. Мөселман бар земстволарда, думаларда тавыш күплеге илә мөселманнардан сайланмак мөмкин булмаса да, берничә мөселман сайламак лазем улсын.

40. Дин һәм җенсиять башкалыгы игътибар кылынмаеп, бөтен халыктан тупланган сәрмая русларның ялгыз үзләренә махсус хаҗәтләренә никадәр сарыф кылыныр. Мөселман хиссасына [өлешенә, үзенә тиешле күләмгә] төшәчәк микъдар мөселманнарның үзләренә вирелер.

41. Урта вилаятьләрдә мөселманнарның эксәре [күбесе] крестьян сословиясеннән хисап кылына. Шул тоткынлык бәндәлек заманаларыннан калма мәнфур [нәфрәт ителгән] исем илә Россиядә һичкем аталмаса иде. Бәлки хөррият вирүче император теләгәнчә, я сельский обыватель, я поселян, я хлебопашец кеби исемнәр илә аталса иде. Шул крестьянин сүзе христианин сүзеннән бозылма сүз булганлыгы өчен, хосусият илә мөселманнар шул крестьянин исеме илә аталмаса иде.

42. Миссионерлык кылучы христианнар ислам балаларын тәрбия итүдән катгый сурәттә мәнгы [туктату, булдырмау] кылынса иде.

43. Нагяһ [көтелмәгәндә, аңсыздан] арттан кылачак бер адәм табылса, ислам руханилары хозурында ля экалле [иң кимендә] бер ай мөддәт [ара, вакыт] вәгазь кылынмак шарт кылынса иде.

44. Ислам дине үзәрендә туган, торган, ислам динендә гомер иткән, һичбер вакыт һичбер җирдә христиан диненә күчмәгән, кәлисә метрикәләрендә исеме язылмаган, асылсыз «отпавший от православия» исеме вирелгән бичара мөселманнар хәзерге хәлләре кеби газапта тотылмаса иде. Бәлки үзләренең миллион кат таләпләре буенча рәсми мөселман хисап кылынса иде. Ул бичаралар вөҗдан куәте илә кәлисәдән, закон куәте илә мәс-

җедтән мәмнүгъ [тыелган] улып, диннән-гыйбадәттән мәхрүмдер.

45. Миссионерлык кылучылар мөселманнарның диннәренә тәгадди итүдән [җәберләүдән, рәнҗетүдән], ялан яла ябу кеби эшләрдән мәнгы кылынса иде. Ул илә эшләрдә хөкүмәт өчен дә, христианлык өчен дә зарардан башка һичбер файда юк.

46. Мәсҗед-мәдрәсә бина итмәк, ислам мәхкәмәләренә адәм тәгаен итмәк кеби хосусларда миссионерлык кылучыларның рәиләре [карашлары] һәм дә мөселманнарның эшләре хакында Синод заключениесе соралмаса иде.

47. Мәктәп-мәдрәсәләргәме, мәсҗедләргәме яхуд башка хәйрат юлларынамы вәкыф кылыныр исә, вакыйфның ихтыярына муафыйк сурәттә вәкыф тәсдыйк кылыныр. Мәктәп-мәдрәсәләр, мәсҗедләр файдасына вәкыф кылынган җирләрдән, йортлардан, маллардан һичбер налог виргу алынмас.

48. Мөселманнарның каберстан җирләре, мәсҗед җирләре мөкаддәс игътибар кылынып, ул җирләрдә мәктәп-мәдрәсә, мәсҗедтән магада [башка, бүтән] һичбер шәй бина кылынмас. Ул җирләр һичбер бәһанә [сылтау, сәбәп] илә алынмас.

49. Россия мөселманнарының петицияләренә кушылып, бөтен милләтләрнең интеллигенцияләре илә бәрабәр, Россия мөселманнары да закон кашында бөтен халыкның гомуми мөсавәтләрен [тигезлекләрен]; диннең, матбугатның, иҗтимагларның [җыелышларның], сүзнең хөрриятләрен таләп итәр. Һәр фәрднең [затның] шәхесе һәр җирдә, һәрвакыт хөр улыр, мәхкәмә карары булынмадыкча, администрация юлы илә һичбер фәрд һичбер вакыт тоткын улмас, хокукта тәхдид [чикләү] сәбәбе кылынмас.

Мөхтәрәм казый Хәсәнгата хәзрәтләренең шул 49 маддәсе әүвәлге ляихәләрдә, проектларда нәкыль [сөйләнгән] кылынмыш маддәләрнең тәкрары [кабатлау] кеби исә дә, үз башына мөстәкыйль сурәттә язылып, бәгъзе мөһим зиядәләренең дә варлыгына күрә, бу раддә тәмам илә нәкыль иттем.

*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчереп,*
*сүзлекне һәм аңлатмаларны Казан федераль университетының*
*Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре*
***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы** әзерләде*